**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НУРЛАТСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

11.05.2018 № 344

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының торак сәясәте бүлеге тарафыннан муниципаль хезмәт күрсәтүнең технологик схемаларын раслау турында

“Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында” 2010 елның 27 июлендә гамәлгә кергән 210-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 2 ноябрендәге “Татарстан республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында” 880 нче карары нигезендә

КАРАР БИРӘМ:

1.Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының торак сәясәте бүлеге тарафыннан муниципаль хезмәт күрсәтүнең технологик схемаларын расларга:

1.1. “2014-2020 елларга Татарстан Республикасында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү” программасы буенча исәпкә кую һәм торак сатып алуга (төзүгә) социаль түләү алу хокукы турында таныклык бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең технологик схемасы (1 нче кушымта).

1.2. “Татарстан Республикасында социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗларны исәпкә кую” муниципаль хезмәт күрсәтүнең технологик схемасы (2 нче кушымта).

1.3. “Торак урыннарына мохтаҗ гражданнарның аерым категорияләрен исәпкә кую” муниципаль хезмәт күрсәтүнең технологик схемасы (3 нче кушымта).

1.4. “Чернобыль АЭСындагы һәлакәт, “Маяк” җитештерү берләшмәсендәге авария нәтиҗәсендә радиация тәэсиренә дучар булган гражданнарны һәм аларга тиңләштерелгән затларны исәпкә кую һәм Дәүләт торак сертификаты бирү буенча” муниципаль хезмәт күрсәтүнең технологик схемасы (4 нче кушымта).

1.5. “Торак шартларын яхшыртуга мохтаҗлар буларак исәпкә кую һәм күчеп китәргә мәҗбүр булганнарга торак сатып алу өчен субсидия бүленүгә Дәүләт торак сертификаты бирү буенча” муниципаль хезмәт күрсәтүнең технологик схемасы (5нче кушымта).

1.6. “Муниципаль торак фондыннан торак урынны социаль наем шартнамәсе буенча гражданга бирү” муниципаль хезмәт күрсәтүнең технологик схемасы (6 нчы кушымта).

1.7. “Социаль түләүләрдән файдаланып торак шартларын яхшыртырга теләк белдергән гражданнарны исемлеккә кертү һәм авыл җирендә торак төзү (сатып алу) өчен социаль түләү бирү турында таныклык тапшыру буенча” муниципаль хезмәт күрсәтүнең технологик схемасы (7 нче кушымта).

1.8. “Муниципаль торак фондыннан хезмәт торак урынын гражданнарга найм шартнамәләре буенча бирү" муниципаль хезмәт күрсәтүнең технологик схемасы (8 нче кушымта).

2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктур үсеш буенча урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче А.С. Әхмәтшин